ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

ДЕКАБРЬ, 2016нчы ел

№3 (20)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**






**1— СПИДка каршы көрәш көне.**

**3 - Халыкара инвалидлар көне**

## Барысы да безнең кулда

"Матурлык дөньяны коткарыр", - диләр. Минемчә, иң матур кешеләр - балалар. Без гаиләдә, мәктәптә тәрбияләнәбез. Ә мәктәп ул - дөньяга, тормышка караш формалаша торган иң изге урын. Бала беренче тапкыр мәктәп-ә килгәч үзенә дуслар таба, алар белән аралаша. Еллар уткән саен ул акыл, тәҗрибә туплый.Аның тормышка үз карашы, һәр нәрсәгә үз фикере барлыкка килә. Ләкин кешеләр табигать тарафыннан шундый төрле итеп яратылганнар. Холык-фигыльләре, кыяфәтләре, социаль хәлләре, дөньяга карашлары белән кешеләр бер-берләреннән шактый аерыла. Безнең арада да төрлеләре бар. Дин юлына кереп киткән, сәламәт яшәү рәвеше алып барган, акыллы, белемле яшьләр белән беррәттән начар гадәтләргә ияргәннә-ре дә бик күп. Мине бигрәк тә наркомания, СПИД дигән зур афәтләр борчый. Элек без бу турыда телевизордан күреп, газета-журналлардан укып белдек. «Ярый әле бездә юк бу чир», дип уйлый идек. Бу баткаклыкка кереп баткач кына алар аның нинди куркыныч икәнен аңлыйлар. Алар инде беркайчан да сәламәт, ирекле була алмыйлар. Кеше үзенең наркоман икәнен аңлаганда бик соң була инде. Ләкин чын наркоманнар да үзләрен наркоман итеп танырга теләмиләр. Алар язмышларына буйсынып, тормыш өчен көрәшсәләр, үзләре өчен яхшырак булыр иде.

**Гөлшат Гайсина**







**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Телефоннар шалтырыйлар... | 2 |
| Белә идегезме? | 3 |
| Якыннан танышыйк! | 4 |
| Иң көчлеләр билгеле | 5 |
| Көлке хикмәте | 6 |
| Ничек актер булырга? | 6 |
| Котлыйбыз! | 7 |

# Телефоннар шалтырыйлар...



Бүгенге тормышны телефоннан башка күз алдына китерүе дә кыен. Ә бит моннан бик күп еллар элек кешеләр бу элемтә чарасыннан башка яшәгән. Алар бер-берсе белән хәбәр йөртүче атчабарлар аша аралашкан. Шулай ук кораб җилкәсенең төсенә, учак төтененә, барабан тавышына да ниндидер мәгълүмат салганнар. Борынгы Рим императоры Юлий Цезарь хакимлек иткән чорда махсус кычкыручылар булган. Алар чылбыр буенча басып, кирәкле яңалыкны бер-берсенә кычкырып әйтә барган. Мондый юл хәбәрне кирәкле урынга сәгатенә йөз километр тизлек белән җиткергән, имеш. Бары тик 19 нчы гасыр ахырында гына ерак араларны якынайтучы чара - телефон барлыкка килә. Аны кем уйлап тапкан, дисезме? Беренче телефон америкалы Александр Белл исеме белән бәйле. Дөрес, тавышны ерак арага электр ярдәмендә җиткерүче бу аппаратны ясауга тагын берничә кеше якын килә. Ләкин алар арасыннан үзенең уйлап тапканын нәкъ Белл беренчеләрдән булып дөньяга таныта. 1876 нчы елның 14 феврале телефонның туган көне санала. Шул ук елның 10 мартында тәүге телефоннан тәүге сүзләр яңгырый: "Мистер Уотсон, монда килегез әле, сез миңа кирәк идегез!" Александр Беллның трубка аша ярдәмчесе Томас Уотсонны чакырып әйткән сүзләре тарихи әйтемгә әйләнде.

Вакыт үтү белән дисклы зур аппаратларны кнопкалы радиотелефоннар алыштырды, кесә телефоннары барлыкка килде. Хәзер инде телефонның нинди генә төрләре юк. Якыннарга, сыйныфташларга, дусларга нидер әйтергә кирәксә, каядыр йөгерәсе юк, тиз генә трубкага үреләбез. Уңайлы нәрсә бу телефон дигәнең! Шулай да радио, кесә телефоннарыннан сәгатьләр буена сөйләшергә ашыкмагыз, кызлар, малайлар. Аның файдасы белән бергә,

## Белә идегезме?

«Үзе бер карыш, сакалы биш карыш» дигән сүзләр әкиятләрдә безгә еш очрый. Күпме озынлыкта булган соң ул сакал? Яисә «Түтәрәм-түтәрәм тарым бар, күтәрә алсаң, барын да ал» дигән башваткычны кем генә белми? Бер түтәрәм тары күпме авырлыкта булган? Моны белү бик кызыклы бит. Күз күреме (тигез урында күреп була торган ара) – 3-4 чакрым. Өрмәк (эт өргән тавышны иштеп була торган ара) – 2-3 чакрым. Ук атымы (атылган укның очу ераклыгына тигез ара) – 0,6 чакрым. Колач – 1,7-1,8 м. Терсәк – 75 см. Адым – 70 см. Тотам (кул яссуы, дүрт илле) – 7,5-8,5 см. Бер илле (бармак юанлыгы) – 1,5 см. Сөям (кече карыш – имән һәм баш бар -маклар арасы) – 16 см.Карыш ( имән һәм чәнчә бармаклар арасы) – 18 см. Пот – 16 кг. Батман – 4 пот чамасы. Кадак (гөрәнке) – 409,5 г чамасы. Мыскал – 1/96 кадак – 4,5 г чамасы.Түтәрәм – нәрсәнең булса да чиреге.Безнең бабайлар шулай ук чиләк, капчык, подаука, коштабак кебек үлчәү берәмлекләре дә кулланганнар.

## Кош оясы ясаганда

Аны агач такталардан да, бүрәнәдән дә (бүрәнәнең эчен чистартып) ясарга була. Фанералар куллану файдалы түгел, клей исен кошлар яратмый. Такталарны шомартмыйбыз – кошлар өчен шулай уңайлы. Сыерчык оясы артык зур булмаска тиеш. Зуррак ояга урнашкан сыерчыклар йомырканы күбрәк сала, нәтиҗәдә, бөтен балаларын да үстереп очырып бетерә алмаска мөмкиннәр.Кош ояларының «авызы»н зур итү дә дөрес түгел. Югыйсә, ояга песиләр һөҗүм итәргә мөмкин. Песи менмәсен өчен оя астына (агачка) тимерчыбыклардан ясалган боҗра беркетергә була. Зур авызлы кош ояларына еш кына тиеннәр дә оялый.Безнең ояга кошлар ояламый башлый икән, аны чистартырга вакыт дигән сүз. Кайнап чыккан су, яисә марганцовкалы су белән эшкәртүнең файдасы, һичшиксез, тиячәк.Кош оясын юлдан, сукмаклардан

# Якыннан танышыйк!





**Укучыларның сорауларына башлангыч сыйныф укытучысы Гирфанова Раилә Наил кызы җавап бирә.**

- Ралия Наилевна, ни өчен сез укытучы һөнәрен сайладыгыз?

- Укытучы һөнәренә мәхәббәтне әнием уятты. Ул үз эшенә тугры калган кеше. Башта мәктәптә рус теле укытты, аннан соң озак еллар буе район мәгариф бүлегендә методист булып эшләде.

**- Электрон технологияләр кертелгәч, укытучының эше җиңеләйдеме?**

- Минем өчен электрон журнал бик җайлы. Кәгазь журналдагы кебек нинди дә булса хата ясаудан куркып тормыйсың. Ә болай барысы да элеккечә инде – бөтен көчеңне укучыларыңны белемле итүгә куясың, аларның уңышларын күреп сөенәсең, уңышсызлыклары булса – борчыласың. Шөкер, хәзер хезмәтебез катлаулы гына түгел, мактаулы да.

**- Раилә Наиловна, беренче эш көнегез ничек үтте?**

Аллага шөкер, көнем уңышлы гына үтте. Кулларына аллы-гөлле чәчәкләр тотып укучыларым килде. . Баштан "Мин талантлы" дигән класс сәгате үткәрдем. Бер төрле танышу дәресе булды ул. Аннан математика дәресе уздырдым, китап белән таныштык, санадык һәм бу көнне күбрәк аралаштык .



**— Газета укучыларыбызга теләкләрегез?**

— Әни буларак теләгем: балалар исән-имин, таза-сау, бәхетле булсын. Укытучы, тәрбияче буларак теләгем: мәктәпкә, укытучыларга булган хөрмәт артсын, мәгариф системасында тотрыклылык урнашсын. — Амин, шулай булсын. Эшегездә һәм тормышыгызда һәрчак уңышлар гына юлдаш булсын!

**Әңгәмәне Рузилә Садртдинова алып барды**

# 12 декабрь – Россия Федерациясе Конституциясе көне

**Экстремаль спорт төрләре белән кызыксынучылар соңгы вакытларда шактый артты. Яшьләр дә, мондый "уен"нарның тормыш өчен куркыныч булуларын белә торып, әлеге спорт төрләре белән шөгыльләнүне хуп күрәләр.**

Күпсанлы акробатик элементлар, зур тизлек (биеклек, тирәнлек), адреналин – бәлки кешене нәкъ менә алар җәлеп итәдер? Теләсә нинди спорт төрендә сәламәтлеккә зыян китерә торган өлеше бар, дию-челәр дә табылыр. Иң мөһиме шунысы истән чыгармаска: сакланып, тренер сүзен тыңлап, игътибар белән шөгыльләнергә кирәк.

**Сигвей полосы.** Атта утырып поло уйнау, күпләр фикеренчә, инде күптән искергән. Ничек кенә булмасын, бүгенге көндә дә әлеге спорт төре белән шөгыльләнүчеләр бар, тик менә атны гына сигвейга алыштырганнар! Әйтергә кирәк, моңарчы инде аны велосипедка утырып та, дөя, хәтта филләргә атланып та уйнаганнар.Сигвей дигән җайланма АКШта бик популяр. Apple компаниясенә нигез салучыларның берсе Стив Возняк та еш кына аның белән йөри. Сигвей үзенең уңайлы булуы белән җәлеп итә. Шуңа да полода ул тулысынча атны алтыштыра ала. Кагыйдәләр бераз үзгәртелсә дә, максат бер үк кала: уенчылар ике командага бүленеп, билгеле бер вакыт эчендә каршы командага махсус кәшәкәләр белән голлар кертергә тиеш. Үз тәнең белән идарә итә белү, акробатик маневрлар ясау таләп итә әлеге спорт төре.

**Ат белән узышу.** Барысы да бер кешенең "мин йөгергәндә атны уза алам" дип мактануыннан башлана. Моны ишеткән Гордон Грин исемле фермер әлеге хикмәтле спорт төренә нигез салучыларның берсе була. Тәүге тапкыр 1980 елда оештырылган мондый ярышның максаты булып ат һәм кешенең 35 километрны калкулыклар аша узуы торган. Әлбәттә, ул чакта ат беренче килгән. Күпмедер вакыттан соң кешеләр ат белән велосипедка утырып ярыша башлаган.

## Юл кагыйдәләре – безнең дусларыбыз!

26 нчы декабрь көнне мәктәбебезгә ЮХИДИ начальнигы Рөстәм Гарипов килде. Ул юл йөрү кагыйдәләре буенча җәяүлеләр транспорт юлын җәяүле юлы аша, урам чатларында исә тротуар линиясе буенча чыгарга тиешлеген кабат аңлатты, юлда машиналар агымы каршы якка булган очракта гына йөрергә һәм автомобильләр хәрәхәт иткәндә юл янында якын йөрмәскә киңәш итте. Җәяүлеләр көннең караңгы вакытында киемнәренә яктылыкны кире кайтара торган элементлар куйсалар үзләре өчен дә, башка юл хәрәкетендә катнашучылар өчен дә куркынычсыз булуын искәртте.



2 нче декабрь көнне Нурлат шәһәренең 9 нчы мәктәбендә Россия дәүләт автоинспекциясенең 80 еллыгына багышлап “Яшь инспекторлар хәрәкәте» конкурсы булып үтте. Бәйгедә 24 команда, барлыгы 96 яшь инспектор катнашты. Конкурста безнең “Добрая дорога” командасы да уңышлы чыгыш ясады.








### Олимпиада — тырыш һәм сәләтлеләр бәйгесе

**Ниһаять, олимпиадаларның район турында җиңүчеләр дә билгеле булды:** инглиз теле буенча Шарапова Лэйсэн белән Шакурова Алсу, тормыш иминлеге нигезләре фәненнән Хәйруллин Булат, Сафиуллин Хәлил призлы урынга ия булса, рус теле буенча Әһлиуллин Аяз, биологиядән Вәгыйзова Ләйсән, җәмгыять белеменнән Гайсина Гөлшат призлы урынга ия булдылар. Ә инде иң-иң бәхетлеләр—Хәйруллин Булат географиядән, Шарапова Ләйсән белән Гафурова Алия татар теленнән ЖИҢҮ яуладылар. II яртыеллыкта алар республикага район данын якларга барачаклар!

**Уңышларыгыз белән котлыйбыз, дуслар! Алдагы бәйгеләрдә дә сынатмассыз дип ышанып калабыз! Уңышлар сезгә!**

# Көлке хикмәте



*****

Укытучы эштән кайтып килгәндә, подъезд төбендә бер бандит ташлана:

- Отдай часы! - ди укытучыга.

Укытучы коты очып, ялвара:

- Часы не отдам!!! Бери классное руководство!!!

****

Әтисе улына:

- Улым, син үсеп життең инде, кем булырга уйлыйсың?

- Әти, мин Кыш бабай булырмын ахры!

- Нишләп? !

- Нишләп дип, чөнки ул Яңа елга кадәр бер атна һәм Яңа елдан соң бер атна гына эшли.

*****

Урыс теле дәресендә:

- Рустем, телефон звОнит или звонИт???

- Белмим, Марья Ивановна, у меня шалтырата!

*****

Бер хәлсез генә бөкре кеше бу-ла. Урамнан барганда, бер малай аның җилкәсенә таш белән бәрә. Бөкре, малайны чакырып ала да, бераз акча биреп::


- Ай, акыллым, бик төз атасың икән, - ди. Аннан, урамнан узып баручы таза кешегә күрсәтеп:

-- Бар әле, әнә шул кешегә дә бәр, ул бай, күбрәк бирер, - ди.

Малай, ышанып, теге кешегә дә бәрә. Шул кеше малайны тотып ала да бик үткәреп яңаклый.

## Уйлап кара әле


Бер шырпыны алып, икенче урынга куйсаң, дөрес мисал килеп чыгар



Җавабтагы 7 саны-ның бер шырпысын алып, 5 тән 6 яса.

## Сабырлар өчен

Вьетнамдагы бер укытучы әлеге башваткычны 8яшьлек укучылары-на чишәргә бирә икән. Алар аны бик тиз чишкәннәр. Шунысы кызык, олылар исә, бу саннар өстендә озак баш ватканнар. Ә син чишә алырсың микән?




## Бер уч бәхет



**Ничек актер булырга? Бу сорауга жавап табуы бер дә авыр түгел. Әлеге хыялны тормышка ашырыр өчен Казан дәүләт мәдәният институтына укырга керергә кирәк. Ә, димәк, кирәкле БДИларны тапшыру гына таләп ителә. 1 процент сәләт, 99 процент тырышлык булса, башка әйбер кирәкми диләр бит.**

Казан дәүләт мәдәният институты һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры 2017-2018 уку елына татар актерлык курсына студентлар кабул итә. Театр факультеты профессиональ театрлар өчен югары белемле артистлар әзерли. Консультацияләр 1 марттан (һәр якшәмбедә) 11.00–13.00 арасында Г.Камал театрында үткәрелә.

Ә 21 февральдә 11.00дә Яр Чаллы шәһәренең «Энергетик» мәдәният сараенда Фәрит Бикчәнтәев театраль факультетының актерлык курсына укырга керергә теләүчеләр белән әңгәмә уздыра.

**Кабул итү имтиханнары:**
1. Рус теле (БДИ);
2. Рус әдәбияты (БДИ);
3. Белгечлек буенча сынау – өч әдәби әсәрне яттан уку (шигырь, мәсәл һәм чәчмә әсәрдән өзек); җыр, бию, музыкаль әсәр башкару;
4. Әңгәмә.

Имтиханнар 17 июльдән 26 июльгә кадәр дәвам итә. 4 бюджет һәм 4 түләүле урын. Абитуриентларның татар телен белүләре мәҗбүри! Кабул итү имтиханнары институтта уза. Студентларга стипендия түләнә, тулай торакта урын бирелә. Егетләр уку чорына армиядә хезмәт итүдән азат ителәләр.

**Укырга керү өчен кирәкле документлар:**
– гариза;
– урта белем турында таныклык;
– паспорт, БДИ тапшыру турында белешмә;
– сәламәтлек турында белешмә;
– 3х4 см зурлыгындагы 6 фоторәсем.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

***Кадерле укучылар, укытучылар, техник хезмәткәрләр һәм әти-әниләр!***

**Сезнең барыгызны да Яңа ел белән котлыйбыз!**

**Сәламәтлек һәм бәхет-шатлык белән тулы көннәр, байлык һәм күңел тынычлыгы сезне читләтеп үтмәсен. Хыялларыгызның һәр барчасы тормышка ашсын, бәхетләрегез ташып торсын! Сезгә укуыгызда һәм эшегездә уңышлар телибез!**

**Сәламәтлек бирсен Яңа ел,
Бәхет булып үтсен түрләргә.
Тигез көннәр, озын гомер бирсен,
Менәр өчен биек үрләргә!**



## Әтием сүзен тыңлыйм

Әти сүзен һәрчак тыңлыйм,
Уңган малай мин үзем.
Юлда күргән җәяүлегә
Игътибарлы һәм түзем.

Машина юлын үз итәм,
Йөримен һәрчак уңнан.
Каршыма килсә, машина,
Уздырам аны сулдан.

Йөри белеп йөрсәң әгәр,
Юл булмас һич куркыныч.
Әти сүзен тыңлаганга
Мин үзем һәрчак тыныч.

Декабрь аенда туучы кадерле укытучыларыбыз һәм техник хезмәткәрләребез:

**Хайруллина Лилия Йосыф кызы,**
**Гыйрфанова Ралия Наил кызы,**
**Әһлиуллина Гөлүсә Дамир кызы,**
**Хисматов Рамил Гариф улы!**

Сезне туган көнегез белән чын күңелдән котлыйбыз. Сезгә нык сәламәтлек, күңел тынычлыгы, гаилә шатлыгы, кайгы-хәсрәтсез көннәр, ак бәхетләр, балаларыгызның һәм оныкларыгызның күңел җылысын тоеп, игелекләрен күреп, бәхетле озын гомер кичерүегезне телибез. Киләчәгегез җыр кебек матур, кояш кебек якты булсын. Туачак таңнарыгыз һәрвакыт нурлы, күк йөзегез һәрвакыт аяз булсын. Гел шулай елмаеп, кешеләрне сөендереп яшәгез!

Декабрь аенда туучы кадерле укучыларыбыз:

Щербаков Тимур, Мишин Ислам, Ахметова Назиля, Гумерова Ләйсән!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

## Туган көн

Гомерең хәзинәсенә
Өстәлде тагын бер ел,
Моңайма еллар үтә дип,
Елмай син — бәхетле бул!
Котлы булсын бәйрәмең,
Тыныч булсын күңелең,
Шатлык-сөенечләр белән
Тулы булсын гомерең!
Гамьле еллар, ямьле көннәр
Телибез чын йөрәктән!
Һич кичекми чынга ашсын
Безнең күркәм теләкләр!




**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**


**“КӨЗГЕ”**

**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович

***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.

(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011

Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.

Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Билданова Фидалия Вазировна

**Урынбасары:** Таһирова Гайшә

**Дизайнер**: Хайбуллина Алсу

**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна

**Редколлегия**: Гайсина Гөлшат, Садртдинова Рузилә, Ситдикова А.лсинә, Ахметова Нәзилә.